РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

04.05.2026

№471-п

Ятим балаларга һәм ата-ана
тәрбиясеннән мәхрүм калган,
вакытлыча тәрбиягә балалар алган
гайләләргә психологик тикшерү уздыру
һәм үткәрү буенча эшче төркем төзү
турында

Россия Федерациясенең Гаилә кодексына, Татарстан Республикасының Гаилә кодексына, 2008 елның 24 апрелендәге №48-ФЗ номерлы «Опека һәм попечительлек турында» Федераль законына, 2026 елның 17 мартындагы №3345/26 номерлы №48-ФЗ Федераль закон, мәгариф һәм фән министрлыгының «2026 елда вакытлыча тәрбиягә балалар алган гайләләрдәге балаларга психологик тикшерү турында" хаты, 2018 елның 19 сентябрендәге №12-18 номерлы «Опекуннар(попечительләр), тәрбиягә бала алган ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның гаиләләрендә тәрбияләнүче балаларның хокукларын яклауның нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында» балигъ булмаганнар эшләре, аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР КЫЛА:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә вакытлыча тәрбиягә балалар алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга психологик тикшерү уздыру һәм үткәрү буенча эшче төркем төзергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә вакытлыча тәрбиягә балалар алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга психологик тикшерү уздыру һәм үткәрү буенча эшче төркеменең составы (кушымта итеп бирелә);

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә вакытлыча тәрбиягә балалар алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга психологик тикшерүне әзерләү һәм үткәрү чаралары планы (кушымта итеп бирелә);

- Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә вакытлыча тәрбиягә балалар алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларга һәм ата-

ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга психологик тикшерүне әзерләү һәм үткәрү турында нигезләмә  (кушымта итеп бирелә);

3. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ белән килешеп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә вакытлыча тәрбиягә балалар алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга психологик тикшерү урыны итеп - Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «"Сәләтле балалар "ОНИКС" мәгариф үзәге» МБМУ базасында эшләүче «Җиде төс» Психологик-педагогик хезмәт урынын билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru адресы буенча «Интернет» информацион-телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы Ә.Ш. Хәнафиевага йөкләргә.

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты  Җитәкчесе  М.Р. Кәримов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының
_______________карары белән
Расланды

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә вакытлыча тәрбиягә балалар алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга психологик тикшерү уздыру һәм үткәрү буенча эшче төркемнең составы**

| | |
|---|---|
| Гарипов Ирек Рамазан улы | Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - Башкарма комитет аппараты җитәкчесе, эш төркеме җитәкчесе |
| Хәнафиева Айгөл Шәкирҗан кызы | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге башлыгы, эшче төркем сәркатибе |
| Эшче төркем әгъзалары: | |
| Әхмәтҗанова Варвара Владимировна | Байлар Сабасы штб «Гимназия» МББУ педагог-психологы (килешү буенча) |
| Нигъмәтуллина Ландыш Каниф кызы | 3 нче номерлы Шемордан «Салават куперы» балалар бакчасы МББКУ педагог-психологы (килешү буенча) |
| Низамиева Рәзилә Вәзих кызы | 6 нчы номерлы Саба «Балачак» балалар бакчасы МББКУ педагог-психологы (килешү буенча) |
| Нурисламова Эльвина Рәмис кызы | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «ОНИКС» сәләтле балалар мәгариф үзәге МББУ педагог-психологы (килешү буенча) |
| Обдирщиков Сергей Андреевич | "Саба үзәк район хастаханәсе" ДАССУ табиб-психиатры (килешү буенча) |
| Самарина Алина Казбек кызы | «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ методисты |
| Хәбибуллина Миләүшә Газинур кызы | «Саба гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ педагог-психологы (килешү буенча) |
| Шакиров Ильфат Фоат улы | «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы |
| Шамиева Феруза Хәбиджан кызы | Шемордан «Үсеш» лицее МББУ педагог-психологы (килешү буенча) |
| Юсупов Марат Рафаэль улы | «Саба үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча) |

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитеты
карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган, вакытлыча тәрбиягә балалар алган гайләләргә психологик тикшерүне әзерләү һәм үткәрү чаралары планы**

| № | Чаралар | Башкару вакыты | Башкару өчен җаваплы затлар |
|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исемлекләрен «Җиде төс» психология-педагогика хезмәтенә һәм «Саба ҮРХ» ДАССУга юнәлтү | ел саен 25 апрельгә кадәр | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге |
| 2 | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исемлекләрен актуальләштерү һәм «Җиде төс» психология-педагогика хезмәтенә һәм «Саба ҮРХ» ДАССУга тапшыру | ел саен 15 августка кадәр | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге |
| 3 | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенә ятим балаларга һәм 3 яшьтән 18 яшькә кадәрге ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга психологик тикшерү үткәрү өчен җаваплы белгечләр күрсәтеп, план-график төзү һәм тапшыру. | ел саен 27 апрельгә кадәр | «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ, «Җиде төс» психологопедагогик хезмәте |
| 4 | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенә, үткәрү даталарын һәм урыннарын күрсәтеп, участок педиатры һәм 3 яшькә кадәр ятим булып ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның патронаж шәфкать туташы күзәтүен үткәрү план-графигын төзү һәм тапшыру. | ел саен 27 апрельгә кадәр | «Саба үзәк район хастаханәсе» ДАССУ |
| 5 | Психологик тикшеренү үткәрү планы-графигын Саба муниципаль районы территориясендәге ятим бала кабул иткән гаиләләргә ирештерү | ел саен 29 апрельгә кадәр | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге |
| 6 | Психологик тикшерү уздыруга балигъ булмаган яисә законлы вәкилнең ихтыяри ризалыгын җыю | ел саен 29 апрельгә кадәр | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7 | Саба муниципаль районы территориясендә яшәүче ятим балаларга һәм 3 яшькә кадәрге ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга участок табибы педиатры һәм патронаж шәфкать туташы эпикриз тутырып күзәтү уткәреп торуы. | ел саен 04 майдан 15 майга кадәр | «Саба үзәк район хастаханәсе» ДАССУ |
| 8 | Саба муниципаль районы территориясендә яшәүче 3 яшьтән 18 яшькә кадәр яшьтәге ятим балаларның һәм ата-ана карауыннан мәхрүм калган балаларның психологик тикшерү үткәрелуе. | ел саен 04 майдан 15 майга кадәр (СПО студентлары өчен ел саен 04 майдан 30.06 кадәр) | «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ, «Җиде төс» психолого-педагогик хезмәте |
| 9 | Балигъ булмаганнарның уңайсыз шартларда булуларына шик туган очракта балигъ булмаганнар һәм законлы вәкилләр белән өстәмә психологик консультацияләр уздыру | психологик тикшерү үткәргәннән соң 10 көннән дә соң булмаганда | «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ, «Җиде төс» психолого-педагогик хезмәте |
| 10 | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенә балигъ булмаганның уңайсыз шартларда булуына шик барлыкка килү яисә рәхимсез мөгамәлә булуында шик туу очраклары турында хәбәр итү | бер көн эчендә | «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ, «Җиде төс» психолого-педагогик хезмәте |
| 11 | Балигъ булмаган баланың уңайсыз шартларда булуына шикләнелгән очракта, балигъ булмаган баланың яшәү шартларын планнан тыш (ашыгыч) тикшерү, әңгәмә үткәрү, мәсьәләнең асылы буенча проект әзерләү | бер көн эчендә | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге |
| 12 | Балигъ булмаганның хәле уңайсыз шартларда булуына шик расланган очракта, балигъ булмаганга балага индивидуаль ярдәм күрсәтү планы төзү | бер көн эчендә | «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ, «Җиде төс» психолого-педагогик хезмәте |
| 13 | Саба муниципаль районы территориясендәге ятим калган балалар тәрбияләүгә алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларның һәм ата-ана карауыннан мәхрүм калган балаларның психологик тикшерү үткәрү буенча отчетларның тәкъдим ителүе | ел саен 25 майга кадәр (СПО студентлары өчен ел саен 19 | «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе» МКУ, «Җиде төс» психолого-педагогик хезмәте |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | августка кадәр) | |
| 14 | Саба муниципаль районы территориясендәге ятим калган балалар тәрбияләүгә алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларның һәм ата-ана карауыннан мәхрүм калган балаларның психологик тикшерү үткәрү буенча ТР МОНга отчетлар тәкъдим ителүе | ел саен 31 августтан 04 сентябрьгә кадәр | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге |

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты
____________________карары белән
Расланды

**Саба муниципаль районы территориясендәге ятим калган балалар тәрбияләүгә алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларның һәм ата-ана карауыннан мәхрүм калган балаларның психологик тикшерүен әзерләү һәм үткәрү турында Нигезләмә**

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә урнашкан гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларга, , стационар учреждениеләрдә торучы ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалардан тыш, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга психологик тикшерү (алга таба – психологик тикшерү) әзерләү кагыйдәләрен билгели.

2. Психологик тест уздыру, кирәкле методикалар кулланып тестлаштырудан гыйбарәт (1 нче кушымта) һәм ятим балаларга һәм әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга (алга таба-балигъ булмаганнар) карата гамәлгә ашырыла.

3. 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы«Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль закон (2 нче кушымта) нигезендә балигъ булмаган баланың яисә аның законлы вәкиленең психологик тикшерүгә ихтыярый ризалыгын алу кирәкле башлангыч шарт булып тора. Конфиденциальлекне саклау өчен җаваплылык Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга психологик тикшерү уздыру буенча эшче төркем (алга таба – эшче төркем) составына керүче һәм тикшерү үткәрүче вазыйфаи затларга һәм белгечләргә йөкләнә.

4. Психологик тикшерү Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба – Башкарма комитеты) тарафыннан билгеләнгән оешмаларда (учреждениеләрдә) үткәреле.

5. Психологик тикшерү - көч куллану, мәрхәмәтсез мөгамәлә, имин булмау факторлары ачыкланган вакытта , шулай ук балигъ булмаганнарны тәрбияләү һәм үстерү өчен киңәшләр эшләү максатларында үткәрелә.

6. Психологик тикшерү үткәрүне оештыру максатлары белән Башкарма комитеты эшче төркемнең составын һәм эшче төркемгә керүче җәлеп ителгән белгечләрнең составын төзи һәм раслый.

7. Эшче төркемгә керүче җәлеп ителгән белгечләргә таләпләр:

«психология», «клиник психология», «социаль педагогика», «педагогик психология» юнәлешләре буенча югары профессиональ белем, психологик диагностика үткәрү осталыклары.

8. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлеге (алга таба – опека бүлеге) үзләрендә исәптә торучы балигъ булмаганнарның исемлекләрен төзи, аларда түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

- фамилия, исем, атасының исеме, яшь (туу датасы, ае, елы);
- белем бирү учреждениесендә белем ала яисә укымый (укучыларда белем бирү учреждениесенең тулы исеме күрсәтелә);
- балигъ булмаган баланың яисә аның законлы вәкиленең психологик тикшерүгә ихтыяри ризалыгы;
- психологик тикшерү үткәрүнең планлаштырылган датасы һәм урыны.

9. План Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана һәм психологик тикшерү үткәрү буенча эшче төркем составына керүче хезмәткәрләргә һәм белгечләргә ирештерә.

10. Психологик тикшерү узган көнне балигъ булмаган бала оешмага законлы вәкиле белән килә.

Эшче төркем тарафыннан һәм психологик тикшерүгә җәлеп ителгән белгечләр тарафыннан балалар өчен процедураның психологик иминлеге тудырылырга тиеш, эшче төркемгә керүче һәм психологик тикшерүгә җәлеп ителгән белгеч тарафыннан баланың телдәге һәм телсез чагылышлары бәяләнә.

11. Балигъ булмаган баланың хәле уңайсыз шартларда дип шикләнгән очракта, психологик тикшерүгә җәлеп ителүче эшче төркем составына керүче белгечләр тарафыннан өстәмә консультация үткәрелә һәм әлеге мәгълүмат Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенә һәм законлы вәкилләренә җиткерелә.

12. Барлык балигъ булмаганнарга психологик тикшеренүнең гомуми дәвамлылыгы 10 эш көненнән, ә өстәмә консультацияләр, тикшеренүләр билгеләгәндә һәм (яисә) балигъ булмаганның хәле турында башка оешмалардан мәгълүмат алырга кирәк булганда, гомуми дәвамлылыгы 15 эш көненнән артмаска тиеш.

13. Психологик тикшерү үткәргәндә алынган белешмәләр, психологик тикшерү барышында уздырылган өстәмә консультацияләр нәтиҗәләре эшче төркем тарафыннан эшкәртелә, тәкъдимнәр белән бәяләмә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенә, балигъ булмаган баланың законлы вәкиленә психологик тикшерү уздырганнан соң 10 көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

14. Психологик тикшерү үткәргәндә балигъ булмаган баланың сәламәтлегенә зыян китерү билгеләре ачыкланган очракта, аларга карата алар хокуксыз гамәлләр нәтиҗәсендә барлыкка килгән дип уйларга нигез бар, эшче төркем бу хакта Эчке эшләр органнарына, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек бүлегенә хәбәр итәргә тиеш.

15. Психологик тикшерү тәмамланганнан соң 15 көннән сорак булмаганда, опека һәм тәрбияләү бүлеге Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты психологик тикшерү нәтиҗәләре буенча отчетны (3нче өстәмә) Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгына тәкъдим итә.

16. Отчет ике экземплярда төзелә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана һәм мөһере белән раслана. Бер экземпляры Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгына җибәрелә, икенче экземпляры Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм тәрбияләү бүлегендә саклана.

Саба муниципаль районы территориясендәге ятим калган балалар тәрбияләүгә алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларның һәм ата-ана карауыннан мәхрүм калган балаларның психологик тикшерүен әзерләү һәм үткәрү турында Нигезләмәгә
1 нче каушымта

**Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар тәрбияләүгә алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим калган балаларны психологик тикшерү методикасы**

| Баланың яше | Тәкъдим ителә торган ысул |
|---|---|
| 3 яшькә кадәрге балалар | Участок табибы педиатр һәм патронаж шәфкать туташы күзәтүе, эпикриз |
| 4-6 яшь | «Дөрес дип санаган йөзне сайла» югары дәрәҗәдә борчылучанлыкны тикшерү проектив тесты (Р.Тэммл, М.Дорки, В.Амен) |
| | Р. Жиля ысулы (баланың анага һәм атага карата конкрет-шәхси мөнәсәбәтен тасвирлаучы 1-4 биремнәр) |
| 7-11 яшь | «Агач» (Л.П. Пономаренко адаптациясе) |
| | Эткиндның төсләр мөнәсәбәте тесты (ЦТО) |
| 12-14 яшь | Люшерның проектив төсләр тесты (электрон вариант) |
| | Ч.Д. Спилбергер югары дәрәҗәдә борчылучанлыкны тикшерү ( Эффектон комплексын кулланып Ю.Л. Ханин адаптациясе) |
| 15-18 яшь | Люшерның проектив төсләр тесты (электрон вариант, Эффектон комплексын кулланып) |
| | Ч.Д. Спилбергер югары дәрәҗәдә борчылучанлыкны тикшерү ( Эффектон комплексын кулланып Ю.Л. Ханин адаптациясе) |
| Үсешләрендә тайпылышлар булг балалар | Өй шартларын һәм балалар-ата-аналар үзара бәйләнешен символлаштыручы фигуралар кулланып сюжетлы-рольле уен |

Саба муниципаль районы
территориясендәге ятим калган
балалар тәрбияләүгә алган
гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим
балаларның һәм ата-ана карауыннан
мәхрүм калган балаларның
психологик тикшерүен әзерләү һәм
үткәрү турында Нигезләмәгә
2 нче кушымта

**Ата-аналарның (законлы вәкилләренәң) баланың шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә һәм аларны өченче якка тапшыруга ризалыгы**

Мин, (фамилия, исем, атасының исеме тулысынча)
_______________________________________________________________
(шәхесен раслый торган документ
төре_____________________________________________
сериясе__________ номеры_________________________ бирелгән (бирелгән дата, органның исеме, документ биргән)
____________________________________________________________________
____________________________________________________________________
_______
түбәндәге адрес буенча яшәүче:
____________________________________________________________________
_______
____________________________________________________________________
_______
балигъ булмаган баланың законлы вәкиле булып торам
ФИО_________________________________________________________________
_______
туу
датасы______________________________________________________________
___
белем бирү оешмасының исеме, класс
____________________________________________________________________
________
____________________________________________________________________
________

«Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законының 9 нчы маддәсенә туры китереп, үз иркем белән һәм үз мәнфәгатьләрем өчен баламның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә, аны автоматлаштыру чаралары кулланып, шулай ук әлеге чараларны кулланмыйча, аның психологик тикшеренүе максатында ризалык бирәм.

Әлеге ризалык нигезендә Мин эшкәртү өчен түбәндәге мәгълүматны бирергә мөмкин: фамилиясе, исеме, атасының исеме, яше, җенесе, илебез, төбәгебез, шәһәребез, теркәлү яисә уку йортының (уку йортының исеме) адресы, элемтә телефоны, электрон почта адресы.

Әлеге ризалык балигъ булмаган баланың югарыда күрсәтелгән максатларга ирешү өчен кирәкле персональ белешмәләренә карата гамәлләрне башкаруга, шул исәптән (чикләнмичә) мәгълүмат алмашу гамәлләрен башкару өчен җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), файдалану, өченче затларга тапшыруны, шәхси

белешмәләрне шәхессезләндерүне, блоклауны, шулай ук теләсә нинди башка гамәлләрне башкаруга бирелә.РФ законнарында каралган.

Әлеге ризалык шәхси мәгълүматларны эшкәртү максатларына ирешкәнче яисә мәгълүматны саклау срогы дәвамында гамәлдә була. Әлеге ризалыкны кире алу опека һәм попечительлек органнарына шәхси белешмәләрне эшкәртүгә ризалыкны кире алу турында язма гариза бирү белән гамәлгә ашырыла. «Шәхси мәгълүматлар турында» Федераль законда каралган максатлар өчен мәгълүматны миңа күрсәтелгән ысулларның берсе белән хәбәр итүегезне сорыйм:_______________________________________________________________

________________

(электрон почта, почта адресы, факс, башка)

Минем шәхси мәгълүматларым үзгәргән очракта, бу хакта опека һәм попечительлек органнарына хәбәр итәргә сүз бирәм.

_______________________ (ФИО) _________________(кул куелу) Дата______

2 нче кушымта
Саба муниципаль районы территориясендәге ятим калган балалар тәрбияләүгә алган гаиләләрдә тәрбияләнүче ятим балаларның һәм ата-ана карауыннан мәхрүм калган балаларның психологик тикшерүен әзерләү һәм үткәрү турында Нигезләмәгә

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында
ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән
мәхрүм калган балаларга
психологик тикшерү уздыру турында хисап.

| № т/б | Яше | Иминлексезлекнең (барлыгы исемлек буенча) | Иминлексезлекнең саны | Иминлексезлекнең саны | Иминлексезлекнең саны | Иминлексезлекнең саны | Иминлексезлекнең ачыкланган фактлары саны | Борчылучанлык дәрәҗәсе югары булган балалар саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | 3 яшькә кадәрле балалар (3 яшь кертелә) | | | | | | | |
| 2. | 4-6 яшь | | | | | | | |
| 3. | 7-11 яшь | | | | | | | |
| 4. | 12-14 яшь | | | | | | | |
| 5. | 15-18 яшь | | | | | | | |
| 6. | Үсешләрендә тайпылышлар булган балалар | | | | | | | |